**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ РАЙОНЫ**
**«БЕРЕЗОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**III ЧАКЫРЫЛЫШ**

**КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 3**

п. Березовка «14» октябрь 2019 ел

**Бөгелмә районы Березовка авыл җирлеге Советының XXXII сессиясенең 2018 нче елның 17 нче октябрендәге «Физик затларның милкенә салым турында»гы 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 нче бүлеге нигезендә

**Березовка авыл җирлеге Советы**
**Карар бирә:**

1. Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 17 нче октябрендә кабул ителгән «Физик затларның милкенә салым турында"гы XXXII сессиясе карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- *4 нче өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:*

*«*4. Физик затларның милкенә салым түләүдән азат итәргә:

4.1. 18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарны;

4.2. әлеге пунктның 4.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

Салым ташламасы салым салынучы түбәндәге төр объектларга карата тәкъдим ителә:

- фатир, фатирның өлешләре яки бүлмә;
- торак йорт яки торак йорт өлешләре;
- гараж яки 30 квадрат метрдан артык булмаган машина урыны.

Гаиләгә туры килгән салым салынучы бер объектка карата салым ташламасы салым түләүче сайлавы буенча билгеләнә.

Салым түләүчеләргә салым ташламасы «Березовка авыл җирлеге» территориясендә даими яшәгән, салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмаган салым салынучы объектка карата, салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә тәкъдим ителә.

- *5 нче өлешнең 1 нче абзацында «физик затлар» сүзләрен төшереп калдырырга.*

2. Әлеге карар 2020 нче елның 1 нче гыйнварыннан, әмма массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Бөгелмә районы**
**«Березовка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Н.Р.Меньшаева**